БАВЛИНСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.05.2020 Баулы шәһәре № 133

Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы
органы әгъзасына, «Баулы шәһәре» муниципаль
берәмлеге сайланулы вазыйфаи
затына карата үз керемнәре, чыгымнары,
милкәте һәм милкәти характердагы йөкләмәләре
турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм
балигъ булмаган балаларының керемнәре,
чыгымнары, милкәте һәм милкәти характердагы
йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки
тулы булмаган мәгълүмат биргән өчен, әгәр дә
бу мәгълүматларны бозып бирү артык зур булмаса,
җаваплылык чараларын куллану турында
карар кабул итү тәртибе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнар, «Муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар, контракт буенча муниципаль вазыйфаларны яисә җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милкәте һәм милкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы, «Муниципаль вазыйфаларга, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасына, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан бирелгән белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан

Республикасы Законнары, «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Баулы шәһәр Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, Баулы муниципаль районы җирле үзидарәсенең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән өчен, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып бирү артык зур булмаса, җаваплылык чараларын (Кушымта) куллану турында карар кабул итү тәртибен расларга.

2. Өлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Өлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Баулы муниципаль районы рәсми сайтына урнаштырырга.

4. Өлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Советы Рәисе урынбасарына йөкләргә.

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы Рәисе

АППАРАТ СОВЕТА
СОВЕТ АППАРАТЫ

Р.Х. Гатиятуллин

Баулы муниципаль районы
Советының 2020 елның
29 нчы май 266 номерлы
карарына кушымта

**Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, «Баулы шәһәре» муниципаль сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, милкәте һәм милкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милкәте һәм милкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән өчен, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып бирү артык зур булмаса, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе**

1. Әлеге тәртип депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге сайланулы вазыйфаи затына карата (алга таба – муниципаль вазифа биләүче зат) үз керемнәре, чыгымнары, милкәте һәм милкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милкәте һәм милкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр (алга таба - керемнәр, чыгымнар, милкәт һәм милкәти характердагы йөкләмәләр турындагы мәгълүматлар) биргән өчен, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып бирү артык зур булмаса, җаваплылык чараларын (алга таба – җаваплылык чаралары) куллану турында карар кабул итү процедурасын регламентлый.

2. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 73-1 өлеше нигезендә керемнәре, чыгымнары, милкәте һәм милкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга түбәндәге җаваплылык чаралары кулланыла:

1) кисәтү;

2) депутатны, әгъзаны Баулы шәһәр Советында аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы Баулы шәһәр Советында вазыйфалар биләү хокукыннан мәхрүм итеп, Баулы шәһәр Советындагы вазыйфадан азат итү;

3) аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итеп, даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү;

4) аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы Баулы шәһәр Советында вазыйфалар биләүне тыю;

5) аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы даими нигездә вазыйфалар башкаруны тыю.

3. Муниципаль вазыйфаларны билэүче затларга карата элеге Тэртипнец 2 пунктында санап үтелгэн җаваплылык чараларының берсен куллану турындагы мэсьэлэ Баулы шэһэр Советы тарафыннан карала.

Күрсэтелгэн мэсьэлэне карау өчен Татарстан Республикасы Президентының Советка кергэн, муниципаль вазыйфаны билэп торучы затка карата җаваплылык чараларын куллану турында «Россия Федерациясендэ җирле үзидарэ оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендэге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 7 өлешендэ каралган гаризасы нигез булып тора.

4. Җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Президенты гаризасы Совет тарафыннан ул кергэн көннэн өч айдан да соңга калмыйча карала.

5. Совет муниципаль вазыйфаны билэүче затка аңа карата җаваплылык чараларын куллану турындагы мэсьэлэне карау хакында күрсэтелгэн мэсьэлэне карау датасына кадэр биш эш көненнэн дэ ким булмаган вакыт эчендэ язма рэвештэ хэбэр итэ.

Совет утырышы урыны һэм вакыты турында хэбэр алган муниципаль вазыйфаны билэп торучы затның килмэве Татарстан Республикасы Президентының җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасын карауга комачауламый.

6. Муниципаль вазыйфаны билэп торучы затка карата җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Президенты гаризасы Совет утырышында «Баулы шэһэре» муниципаль раслаган Советның Регламентында билгелэнгэн тэртиптэ карала (регламентны раслаган карар реквизитлары) (алга таба – Регламент).

Күрсэтелгэн мэсьэлэне караганда муниципаль вазыйфаны билэп торучы затка тапшырылган мэгълүматлар буенча аңлатмалар бирү мөмкинлеге бирелергэ тиеш.

Муниципаль вазыйфаны билэүче затка карата җаваплылык чараларының берсен куллану турындагы мэсьэлэне караганда депутатлар тарафыннан мэнфэгатьлэр конфликтын булдырмау һэм җайга салу буенча талэплэр үтэлергэ тиеш. Совет утырышында рэислек итүче депутатларга мэнфэгатьлэр каршылыгы булу яки каршылыкның барлыкка килү мөмкинлеге турында хэбэр итү турында тэкъдим итэргэ тиеш.

Мэнфэгатьлэр конфликтын булдырмау яки җайга салу максатларында, мэнфэгатьлэр конфликтын яклаучы депутат карар кабул итүдэн рэислек итүче тарафыннан читлэштерелэ.

7. Татарстан Республикасы Президенты гаризасын карау нэтиҗэлэре буенча муниципаль вазыйфаны билэүче затка карата җаваплылык чараларын куллану яисэ җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турында карар кабул ителэ.

Элеге карар Регламентта билгелэнгэн тэртиптэ кабул ителэ.

Татарстан Республикасы Президенты гаризасы аңа карата кергэн депутат тавыш бирүдэ катнашмый.

8. Җаваплылык чарасын куллану турындагы карар гаделлек, туры килү, пропорциональ булу һәм кире кайтмау принципларына таянып, кылынган коррупцион хокук бозуның характерына, аның кискенлегенә, нинди шартларда кылынганлыгына бәйле рәвештә, шулай ук муниципаль вазыйфаны башкаручы затның үз вазыйфаи бурычларын (вәкаләтләрен) үтәүдә элеккеге нәтиҗәләре, аның коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән башка чикләүләрне, тыюларны һәм бурычларны үтәү нәтиҗәләре нигезендә кабул ителә.

Хисап чорында керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән өчен бары тик бер генә җаваплылык чарасы кулланылырга мөмкин.

9. Җаваплылык чарасын куллану турындагы карарда коррупцион хокук бозуга күрсәтмә, муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан бозылган норматив хокукый актлар нигезләмәләре, карарга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирү хокукы булырга тиеш.

10. Җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарда мондый баш тартуның дәлилләнгән нигезе булырга тиеш.

11. Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарның күчермәләре алар кабул ителгәннән соңгы биш эш көне эчендә муниципаль вазыйфа биләүче затка имза куйдырып тапшырыла яисә тапшыру турында белдерү кәгазе белән бергә почта аша җибәрелә, шулай ук Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә.

Җаваплылык чарасын куллану турындагы карарны муниципаль вазыйфаны биләүче затка җиткерү мөмкин булмаса яки күрсәтелгән зат карарны имза куеп алудан баш тартса, Баулы шәһәр Советы Аппаратының кадрлар белән тәэмин итү бүлеге начальнигы тарафыннан югарыда күрсәтелгән затның җаваплылык чарасын куллану турындагы карар белән танышудан баш тартуы яисә аңа бу карар турында хәбәр итү мөмкинлеге булмау турында акт төзелә.

12. Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.